Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Чишмә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**10 ноябрь 2022 ел** **№ 1**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 10 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Чишмә торак пункты террито-риясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакы-тлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы":

- Чишмә авылда урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча электрик эшләре өчен түләү һәм башка агымдагы чыгымнар.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 37 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 22 кеше, бу – 59,4% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 22 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Чишмә торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» Чишмә торак пункты территориясендә, I төркем инвалидларыннан, ялгыз картлардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган затлардан һәм шәхесләрдән тыш иректән мәхрүм итү урыннарында булганнардан тыш, яшәү

урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Чишмә авылда урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча электрик эшләре өчен түләү һәм башка агымдагы чыгымнар.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Авыл җирлеге башлыгы А. А. Нәфыйков